

Кадошкино урта мәктәбе базасында «Ел укытучысы-2019» һонәри осталык конкурсынын район этабы узды. Анда vзләрен һәм коллективларын тәкъдим итvче дvрт педагог катнашты.      Латыш урта мәктәбенен математика укытучысы Роза Равил кызы Бадамшина, Большие Поляны топ мәктәбенен туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева, Адаш урта мәктәбенен чит телләр укытучысы Татьяна Федоровна Кадейкина, Кадошкино урта мәктәбенен рус теле укытучысы Светлана Александровна Псянина ярышта коч сынаштылар; педагоглар vзләренен белемнәрен һәм осталыкларын кvрсәттеләр. Жюри әгъзаларына 2019 елда районнын ин яхшы педагогы исеменә лаеклы кандидат сайлау жинелләрдән булмады. Ул Светлана Александровна Псянина булды.

Укытучы һонә-рендә очраклы кешеләр юк. Аларнын тормышы - кvптавышлы укучыларда, балалар доньясында, тәрбиядә кvргән педагогик хезмәт бәхете. Аларнын һәркайсы горур укытучы исемен йортә.